| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 июля 2019 г. № 3549

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 нче карары белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ санлы Законы, Шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 нче карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 нче карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 нче, 2017 елның 14 апрелендәге 2234 нче, 2017 елның 24 июлендәге 4318 нче, 2017 елның 25 сентябрендәге 5702 нче, 2017 елның 27 сентябрендәге 5755 нче, 2017 елның 23 ноябрендәге 7195 нче, 2017 елның 7 декабрендәге 7601 нче, 2018 елның 8 августындагы 4481 нче, 2018 елның 19 сентябрендәге 5336 нчы, 2018 елның 26 сентябрендәге 5567 нче, 2018 елның 16 ноябрендәге 6757 нче, 2018 елның 13 декабрендәге 7452 нче, 2019 елның 29 мартындагы 1612 нче карарлары редакциясендә) расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 бүлекнең «Халыкның аз керемле категорияләренә, авыр тормыш хәлендә калган затларга матди ярдәм күрсәтү» I бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| 2. | Янгын вакытында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә туганлык мөнәсәбәтләрендә булган затның үлеме аркасында | Башкарма комитет | 01.01.2019-31.12.2019 | Кеше саны | 0 | 0 | 1 | 0 | 0 | 20,0 Муниципаль бюджет |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яисә башка җиңеп чыга алмаслык көчләр нәтиҗәсендә авыр тормыш хәлендә калган затларга матди ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | |

- «Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | | | | | | | 85,0 Муниципаль бюджет | 81,5 Муниципаль бюджет | 104,0 Муниципаль бюджет |

2) 7 бүлекнең «Бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү» II бүлекчәсендә:

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | 9 май – Җиңү көне уңаеннан Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм катнашучыларына истәлекле бүләкләр | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте | 1-10 май | Кеше саны | 60 | 60 | 60 | 135,0 Муниципаль бюджет | 127,5 Муниципаль бюджет | 78,0 Муниципаль бюджет |

түбәндәге эчтәлектәге 10 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Мактаулы гражданнарны, Яр Чаллы шәһәре һәм Татарстан Республикасы үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны җирләү буенча чаралар | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте | 01.01.2019-31.12.2019 | Кеше саны | 0 | 0 | 1 | 0 | 0 | 18,0 Муниципаль бюджет |

- «Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | | | | | | | 999,18 Муниципаль бюджет | 1022,74 Муниципаль бюджет | 806,0 Муниципаль бюджет |

3) 7 бүлекнең «Балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру» IV бүлекчәсендә:

- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Бөек Ватан сугышы ветераннарын, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, беренче төзүче ветераннарны календарь бәйрәмнәр белән котлау | Башкарма комитет | Ел дәвамында | Кеше саны | 300 | 300 | 300 | 0 | 0 | 348,0 Муниципаль бюджет |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (23 февраль, 8 Март, 9 Май), шәһәр һәм республика үсешенә зур өлеш керткән юбилярларны (90, 95, 100 яшь һәм өлкәнрәкләр) котлау | | | | | | | | | |

- «Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | | | | | | | 1494,8<br>Муниципаль бюджет | 1580,8<br>Муниципаль бюджет | 1800,0<br>Муниципаль бюджет |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе<br>вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев